| МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

__18.12.2023__ Казан ш. №__265-ОД__

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Энергия ресурсларының нәтиҗәле технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр күләмен һәм бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктындагы икенче абзацы, бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгели торган, норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга карата Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы автоном учреждениеләренә башка максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгеләргә вәкаләтле булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 28 февралендәге 178 номерлы карары белән билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә

**б о е р ы к б и р ә м:**

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Энергия ресурсларының нәтиҗәле технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр күләмен һәм бирү шартларын билгеләү тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы үзенә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт автоном учреж-дениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә «2014-2024 елларга Татарстан Республикасының икъти-садый үсеше һәм инновацияле икътисады» дәүләт программасының «2015-2024 елларга Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру» ярдәмче программасы чараларын 2022-2024 елларда гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 21 мартындагы 47-ОД номерлы;

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы үзенә карата гамәлгә куючы функ-цияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт автоном учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә «2014-2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацияле икътисады» дәүләт программасының «2015-2024 елларга Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру» ярдәмче программасы чараларын 2022-2024 елларда гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 21 мартындагы 47-ОД номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 6 декабрендәге 255-ОД номерлы;

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы үзенә карата гамәлгә куючы функ-цияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт автоном учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә «2014-2025 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацияле икътисады» дәүләт программасының «2015-2025 елларга Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру» ярдәмче программасы чараларын 2022-2025 елларда гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 21 мартындагы 47-ОД номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 26 октябрендәге 195-ОД номерлы.

3. Җыелма бүлеккә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алганнан соң бер эш көне эчендә Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Боерык 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрының беренче урынбасары Р.М.Карповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы

Премьер-министры урынбасары –
министр О.В. Коробченко

Татарстан Республикасы
Сәнәгать һәм сәүдә
министрлыгының 2023 елның
________________ ______
номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Энергия ресурсларының нәтиҗәле технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр күләмен һәм бирү шартларын билгеләү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип, Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Энергия ресурсларының нәтиҗәле технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә (алга таба – Учреждение) башка максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) күләмен һәм бирү шартларын билгеләү механизмын билгели.

2. Субсидияләр Учреждениегә түбәндәге максатларда бирелә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 октябрендәге 823 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасы структурасына керә торган «Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру» региональ проектын (алга таба – региональ проект) гамәлгә ашыру кысаларында чаралар үткәрү;

Учреждение хезмәткәрләренә түләүләрне гамәлгә ашыру;

3. Учреждениегә субсидияләр, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы буларак, тиешле финанс елына (тиешле финанс елына һәм план чорына) Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

## II. Субсидияне бирү шартлары һәм тәртибе

4. Субсидияне алу максатында Учреждение Министрлык адресына субсидия алу өчен гариза (алга таба – гариза) бирә, ул түбәндәге документларны үз эченә ала:

әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән максатларга субсидияләр бирү кирәклеген нигезләгән аңлатма язуы, тиешле эшләрне башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) башлангыч сметаны кертеп;

региональ проектны гамәлгә ашыру кысаларында субсидия бирелә торган очракта чаралар программасы;

түләүләр алучы физик затлар саны һәм мондый түләүләр төрләре турында мәгълүмат, әгәр субсидия Учреждение хезмәткәрләренә түләүләр башкару өчен бирелсә;

субсидия алу өчен гариза тапшыру көненә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага салым органы белешмәсе, ул Учреждениедә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле процентлар буенча үтәлмәгән бурычның булмавын расларга тиеш;

гариза бирелгән көнгә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага булган торышында Учреждениенең Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиешле, түләү вакыты узган бурычларның, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрнең, бюджет инвестицияләренең булмавы турында җитәкче һәм баш хисапчы тарафыннан имзаланган, Учреждение мөһере (булган очракта) белән беркетелгән белешмә, Учреждениене үзгәртеп кору яки бетерү, аварияле (гадәттән тыш) хәлне булдырмый калу, аварияле (гадәттән тыш) хәл барлыкка килгән очракта аның нәтиҗәләрен бетерү һәм торгызу эшләрен башкару, законлы көченә кергән суд актлары, башкару документлары буенча бурычларны каплау очракларыннан тыш, шулай ук федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында билгеләнгән башка очраклардан тыш.

Тапшырылган документлар аңлаешлы итеп бастырылган булырга тиеш. Учреждение мөһере (булган очракта) белән беркетелгән һәм вәкаләтле затның имзасы белән таныкланган яисә Учреждение җитәкчесе тарафыннан үз кулы белән таныкланган төзәтүләрдән тыш, чистартулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми. Документларның күчермәләре Учреждениенең мөһере (булган очракта) белән беркетелергә һәм моңа вәкаләт бирелгән затның имзасы белән таныкланган яисә Учреждение җитәкчесенең үз кулы белән таныкланган булырга тиеш. Учреждение җитәкчесенең язма мөрәҗәгате Учреждение мөһере (булган очракта) белән беркетелергә һәм вәкаләтле затның имзасы белән таныкланырга яки Учреждение җитәкчесе тарафыннан үз кулы белән расланган булырга тиеш. Субсидия алу өчен документлар әзерләүнең барлык чыгымнарын Учреждение үз өстенә ала.

Учреждение тарафыннан документлар, электрон документ әйләнеше системасын кулланып, электрон рәвештә җибәрелгән очракта, алар Учреждение җитәкчесенең яисә Учреждение җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручының электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш.

5. Гариза Министрлык тарафыннан кергән көнендә теркәлә.

Министрлык әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документларны алганнан соң 10 эш көне эчендә андагы мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә һәм субсидия бирү яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

6. Гариза бирү көненә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага Учреждение түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

Учреждениенең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пеняларны, штрафларны түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмаска тиеш;

Учреждениенең, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарып бирү түләү вакыты узган бурычлары юк.

7. Учреждениегә субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

Учреждение тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

Учреждение тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

8. Субсидия бирүдән баш тарткан очракта, Учреждение әлеге Тәртипнең 4 пунктында каралган документларны Министрлыкка кабат тапшырырга хокуклы.

9. Региональ проектны гамәлгә ашыру кысаларында субсидия күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнә.

Учреждение хезмәткәрләренә түләүләрне гамәлгә ашыруга субсидия күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыклары белән билгеләнә.

10. Субсидия бирү максатларына карап, аны бирү нәтиҗәләре:

Учреждениенең әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада билгеләнгән региональ проект нәтиҗәләре (ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) күрсәткеченә ирешүе;

Учреждение хезмәткәрләренә түләүләрне башкаруга бирелгән субсидия исәбенә кабул ителгән йөкләмәләр күләме (100 процент күләмендә).

11. Субсидия бирү турында карар кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә Министрлык һәм Учреждение Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән типлаштырылган форма буенча килешү (алга таба – килешү) төзиләр, анда, шул исәптән, түбәндәгеләр була:

субсидия бирү максатлары (әгәр субсидия әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 2 абзацына ярашлы рәвештә, региональ проектның исемен күрсәтеп бирелсә);

субсидияне бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре;

субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планы;

субсидиянең күләме;

субсидияне күчерү вакыты (графигы);

хисаплылык тапшыру чорлары һәм тәртибе;

Учреждение килешүдә билгеләнгән субсидия бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәмәгән очракта, субсидия суммаларын кире кайтару тәртибе һәм чорлары;

килешүгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән Министрлыкка субсидия бирү өчен элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары кимегән очракта да;

Министрлык карары буенча килешүне берьяклы тәртиптә вакытыннан алда туктату нигезләре, шул исәптән түбәндәгеләргә бәйле рәвештә:

Учреждениене үзгәртеп кору (кушу рәвешендә үзгәртеп корудан тыш) яисә бетерүгә бәйле рәвештә;

Учреждение тарафыннан әлеге Тәртиптә һәм (яки) килешүдә билгеләнгән субсидия бирү максатларын һәм шартларын бозу;

Учреждение тарафыннан килешүне берьяклы тәртиптә өзүнең тыелган булуына бәйле рәвештә.

Кирәк булуга карап, Министрлык һәм Учреждение килешүгә өстәмә килешү яки Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бер төр үрнәкләр нигезендә килешүне өзү турында килешү төзи.

12. Министрлык килешүдә каралган чорда субсидияне Учреждениенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетына күчерә.

## III. Хисаплылыкка карата таләпләр

13. Учреждение Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

квартал саен, хисап кварталыннан соңгы өч эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидияләр чыганагы булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап һәм субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап. Хисапларның формалары килешүдә билгеләнә;

хисап елының соңгы аеның 25 нче көненнән дә соңга калмыйча, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планын гамәлгә ашыру турында Министрлык тарафыннан расланган форма буенча хисап.

Тапшырыла торган хисаплылык һәм кушымта итеп бирелә торган документлар аңлаешлы итеп бастырылган булырга тиеш. Учреждение мөһере (булган очракта) белән беркетелгән һәм вәкаләтле затның имзасы белән таныкланган яисә Учреждение җитәкчесе тарафыннан үз кулы белән таныкланган төзәтүләрдән тыш, чистартулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми.

Министрлыкка тапшырылган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык Учреждениегә йөкләнә.

14. Министрлык килешүдә өстәмә хисаплылык бирү формаларын һәм чорларын билгеләргә хокуклы.

## IV. Субсидияне бирү максатлары, шартлары үтәлешенә контрольлекне һәм аларны үтәмәгән өчен җаваплылыкны гамәлгә ашыру тәртибе

15. Министрлык һәм вәкаләтле дәүләт финанс контроле органы Учреждениегә субсидия бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе үтәлүгә карата мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра.

16. Учреждение субсидия алу өчен яки субсидиядән файдалану турында төгәл булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырган өчен, әлеге Тәртип нигезендә субсидия бирү шартларын һәм тәртибен бозган, шулай ук субсидияне тоту максатларын бозган, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап һәм (яки) субсидияне бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап һәм субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүнең чаралар планын гамәлгә ашыру турында хисап тапшырмаган өчен, субсидияне максатчан кулланмаган, әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасында билгеләнгән нәтиҗәләр (ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторларына) күрсәткечләренә ирешмәгән өчен җаваплы була.

Учреждениене җаваплылык чараларын куллanudан азат итү өчен нигез булып

Учреждение тарафыннан тиешле йөкләмәләр үтәлешенә комачаулый торган, җиңеп булмаслык шартларның барлыкка килүе турында документаль раслама тора.

17. Министрлык һәм вәкаләтле дәүләт финанс контроле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә Учреждениенең субсидия бирү вакытында билгеләнгән максатларны һәм шартларны үтәмәве, әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасында билгеләнгән нәтиҗәләргә (ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторларына) ирешмәве ачыкланган очракта, Учреждение тарафыннан тиешле таләп алынганнан соң субсидия 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

18. Әлеге Тәртипнең 17 пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару чорын бозган очракта, Министрлык әлеге чор узганнан соң, эш көннәрендә санала торган җиде көн эчендә әлеге акчаларны Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү буенча чаралар күрә.

19. Агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидия акчалары әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә билгеләнгән максатларга ирешү өчен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Министрлык Учреждениенең финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып агымдагы финанс елының 1 гыйнварына тотылмаган субсидиянең калган өлеше булып торган, үтәлмәгән йөкләмәләр булуы турындагы, субсидия бирү елыннан соңгы елның 20 эш көне эчендә җибәрелгән мәгълүматы (алга таба – Учреждениенең субсидиянең калган өлеше буенча мөрәҗәгате), шулай ук учреждениенең әлеге йөкләмәләре (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) булуын һәм аларның күләмен раслый торган документлар (документларның күчермәләре) нигезендә агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидиянең калган өлешен әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә максатларга ирешү өчен юнәлдерү зарурлыгы булуы турында карар кабул итә.

Министрлык агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидиянең калган өлешен әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә чираттагы финанс елында максатларга ирешү өчен юнәлдерү зарурлыгы булуы турындагы карарны Учреждениенең субсидиянең калган өлеше буенча мөрәҗәгате алынган көннән башлап биш эш көне эчендә кабул итә.

20. Агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидия акчаларының калдык өлешен юнәлдерүдә ихтыяҗ булу турындагы карарга ярашлы рәвештә, күрсәтелгән субсидиянең калган өлеше чираттагы финанс елында әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән максатларда кулланылырга мөмкин.

21. Агымдагы финанс елында финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган, Учреждение тарафыннан әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә билгеләнгән максатларга ирешү өчен элегрәк түләнгән түләүләрне кире кайтарудан акча күчкән очракта, Министрлык учреждениенең финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып учреждение тарафыннан элегрәк башкарылган түләүләрне кайтарудан алынган акчалар торган үтәмәгән йөкләмәләр (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) булуы турында субсидия бирелгән елдан соңгы елның 20 эш көне эчендә җибәрелгән мәгълүматы (алга таба – Учреждениенең элегрәк башкарылган түләү-ләрдән алынган акчалар буенча мөрәҗәгате), шулай ук

учреждениенең әлеге йөкләмәләре булуын һәм аларның күләмен раслый торган документлар (документ-ларның күчермәләре) нигезендә әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә билгеләнгән максатларга ирешү өчен учреждение тарафыннан аларны файдалану турында карар кабул итә.

Министрлык әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән максатларга ирешү өчен финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган, Учреждение тарафыннан элегрәк башкарылган түләүләрне кире кайтарудан күчкән акчаларны агымдагы финанс елында файдалану турындагы карарны Учреждение элегрәк башкарылган түләүләрдән алынган акчалар буенча мөрәҗәгать иткән вакыттан башлап биш эш көне эчендә кабул итә.

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Энергия ресурсларының нәтиҗәле технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр күләмен һәм бирү шартларын билгеләү тәртибенә 1 нче кушымта

**Нәтиҗәләрнең күрсәткечләре**
**(ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)**

| Т/с | Региональ проект күрсәткечләре | Үлчәү берәмлеге (ОКЕИ буенча) | Төп мәгънәсе | | Вакыты, ел | | | Арту/кимү билгесе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | билгесе | ел | 2024 | 2025 | 2026 | |
| 1 | Предприятиеләргә хезмәт житештерүчәнлеген арттыру буенча каралган ярдәм чаралары турында хәбәр ителгән | шартлы берәмлекләр | 300 | 2023 | 500 | 500 | 500 | арта баручы |
| 2 | Предприятиеләрнең нәтиҗәлелеген арттыру темасына семинарлар, утырышлар, түгәрәк өстәлләр уздырылган | шартлы берәмлекләр | 3 | 2023 | 3 | 3 | 3 | арта баручы |
| 3 | ppt.tatarstan.ru сайтына керү тәэмин ителгән | мең данә | 20 | 2023 | 30 | 30 | 30 | арта баручы |
| 4 | Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру эшен алып бару буенча эшче төркемнәр оештырылган | шартлы берәмлекләр | 134 | 2023 | 178 | 178 | 178 | арта баручы |
| 5 | Предприятиеләргә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча методик ярдәм күрсәтелгән | шартлы берәмлекләр | 134 | 2023 | 178 | 178 | 178 | арта баручы |
| 6 | Предприятиеләр өчен «җитештерү һәм офис процесслары фабрикаларында» укыту тренинглары үткәрү тәэмин ителгән | шартлы берәмлекләр | 15 | 2023 | 15 | 15 | 15 | арта баручы |
| 7 | Югары белем бирү оешмалары, һөнәри белем бирү оешмалары, гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен «җитештерү һәм офис процесслары фабрикаларында» укыту тренинглары үткәрү тәэмин ителгән | кеше | 16 | 2023 | 48 | 48 | 48 | арта баручы |